РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы,
Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2017 ел № 16

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

“Сез, 2018 елда үзара салым кертүгә Әсәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

1) Әсәй авылы, Митрәй авылы юлларында кар чистарту;
2) Авыл җирлеге территориясендә чүп-чардан арындыру;
3) Бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
4) сүүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
5) янгын сүндерү бүлегенең электр энергиясе, янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү;
6) Митрәй авылы мәдәният йортын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:

ТР, Азнакай муниципаль районы,Әсәй ав., Үзәк ур., 38Б й.

- веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык Л.М. Вәлиева